# Иҗади сәхифә

№ 3 март, 2020

Сәхифәне оештыручылар: 3 нче мәктәпнең татар теле
һәм әдәбияты укытучылары методик берләшмәсе




## Тарих эзләре буйлап...




Хәзерге Татарстан территориясе XV гасырда Алтын Урдадан аерылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән Казан ханлыгы территориясендә урнашкан.
Соңрак шул ук территориядә Идел буе болгарларының Урта гасыр дәүләте төзелә

XV гасыр башында Олы-Мөхәммәд Казан ханлыгының Алтын Урдадан бәйсез булуы турында игълан итә. Яңа дәүләт Мәскәү белән мөстәкыйль рәвештә мөнәсәбәтләр төзи башлый.





1920 елның 27 маенда Халык Комиссарлары Советы Рәисе В.И. Ленин тарафыннан ТАССР төзелү турындагы Декрет имзалана һәм шул ук елның 25 июнендә республика оештырылып, тәүге конституциясе проекты кабул ителә.



СССР таркалганнан соң, Татарстан хәзерге Россия дәүләте составына керә. 1990 елның 30 августыннан аның рәсми исеме- **Татарстан Республикасы.**

Яңа республикага зур сынаулар аша үтәргә туры килә. 1921 еллардагы ачлык афәтендә 600 мең кешенең гомере өзелә, колхозлаштыру елларында, сәяси репрессияләр чорында күп кеше корбан була. Зур югалтуларга карамастан, Татарстан кыска вакыт эчендә социаль-икътисади үсешкә йөз тота.

Татарстан – җир асты байлыклары белән данлыклы, ә иң зур байлыгы – талантлы, уңган күп милләтле халкы: татарлар, руслар, чувашлар, удмуртлар, марийлар, мордвалар, һәм башкалар. Бүген Татарстанда 115 милләт халкы яши. Татарстанның башкаласы- Казан шәһәре. Казан- Россиядә иң борынгы мәгариф үзәкләренең берсе. Татарстанда 30дан артык югары уку йорты (шул исәптән 16 дәүләт уку йорты) бар, аларның күбесе Казанда урнашкан.

## 2020 нче ел — ТАССР төзелүнең 100 еллыгы елы!

**Ренат ХАРИС**
**ТАТАРСТАН**

Татар иле Татарстан,
Син яңадан калыктың.
Син - рухы, көче, намусы
Татар дигән халыкның.

Күп илләрдән калыштың син,
Күрдең алар узганны...
Әкрен генә күмә барды
Сине тарих тузаны.

Һәм син яңадан калыктың!
Иртә чыктылар ясин...
Әй, Бөек Болгар оныгы,
Тарихлы да, яшь тә син.

Көчле дә син, житез дә син -
Атлан акбүз атыңа
Һәм куа чык алга киткән
Ил-дәүләтләр артыннан!

Яшелле, аклы, кызыллы
Әлемең җилфердәсен,-
Әй, Казан ханлыгы улы,
Тарихлы да, яшь тә син!

Олпат та син, горур да син,
Ниятең пакьдин пактер-
Син шатлыктан елый белгән
Баһадир кебек матур!

Татар иле Татарстан,
Син яңадан калыктың;
Син - рухы, көче, намусы
Татар дигән халыкның!

## Муса Җәлил исемендәге мәртәбәле уку йорты.

Минзәлә педагогия училищесы (хәзерге көллият) ачылуына быел 88 ел була. Аз вакыт түгел . Бердәм, эшкә сәләтле, даими рәвештә яңаручы коллективның көндәлек тырыш хезмәт нәтиҗәсе бу. Бу еллар эчендә училище республика һәм ил өчен 20 меңнән артык татар һәм рус башлангыч мәктәпләре укытучысы, балалар бакчалары тәрбиячеләре, хезмәт чит телләр һәм информатика укытучылары әзерләгән. Колледжның тарихы ерак 1932 нче елның 1 нче сентябреннән башланып китә. 1930 елда Совет хөкүмәте мәктәп яшендәге балаларны гомуми башлангыч укыту турында закон чыгара. Яңа мәктәпләр ачыла башлый. Укучылар контингенты арта. Укучыларны укыту өчен укытучылар кадрлары кирәк була. ТАССР Халык мәгарифе комиссариаты Минзәлә шәһәрендә педагогика училищесын ачу мөмкинлеге ала, аның өчен уңайлы бина һәм тиешле кадрлар булдырыла. 1932-1933 уку елында 1 нче курсның 2 рус һәм татар төркеме ачыла.



Газизов Данил,
3 нче В сыйныфы

### Татарстан- минем Ватаным

Татарстанның табигате матур һәм бай. Калын зур урманнар да, тигез далалар да бар анда. Урманнарда төрле агачлар үсә-төз наратлар, нык имәннәр, каеннар, юкәләр, чыршы агачлары да бар. Куе агачлар арасында, куакларда зур мөгезле пошилар, аюлар, бурсыклар, бүреләр, төлкеләр, куяннарны очратасың. Татарстан- бай ил. Кырларында арыш, бодай, арпа, борчак, карабодай , төрле яшелчәләр үсә.Җир астында нефть, газ, ташкүмер һәм башка байлыклар күп.

Ә Татарстанның башкаласы-Казан.

Мин үз Ватанымны яратам.

Искандирова Регина, 3 нче В сыйныфы

## Минем Минзәләм

Мин Татарстан Республикасында яшим. Татарстан Республикасының башкаласы- Казан. Ул бик зур һәм матур шәһәр. Анда тарихи урыннар бик күп.

Минзәлә- минем туган шәһәрем. Ул кечкенә һәм тыныч шәһәр. Минем туган ягымда зур урманнар, Минзәлә елгасы, матур яңартылган күпер бар. Шәһәремдә 3 спорт комплексы эшли. Бу бассейн, боз сарае, теннис.

Ләкин мин шәһәремдә балалар өчен күңел ачу оешмаларының күбрәк булуын теләр идем. Мин Минзәлә шәһәрен бик яратам, чөнки монда минем иң кадерле кешеләрем - гаиләм яши.

9 нчы А сыйныф укучысы , Муллахметова Алия.



****

### Туган ягым-Минзәлә


Урманга бай, суга бай.
Туган ягым- Минзәлә.
Мул уңышлар гөрләп үсә
Кырларында Минзәлә.

Балкый күперең утлары
Якты таңнарга кадәр.
Минзәләне оныта алмассың
Бер килеп күрсәң әгәр.

Гарипов Тимур, 6 нчы Б сыйныфы.

***





Секунова Карина, 3 нче В сыйныф

**Мәкальләр**

* Алтын-көмеш яуган җирдән туган-үскән ил артык.
* Асыл кеше алтын дип үлмәс, халкым дип үләр.
* Ата-бабам торган җир,
Кендек каным тамган җир.
* Атаң да җир, анаң да җир.
* Ат туйган җиренә,
Ир туган иленә тартыр.
* Аягы яман түрне болгар,
Авызы яман илне болгар.
* Бердә түгел, илдә көч.
* Береккән ил бозылмас.
* Бер төкерсә, бер була,
Ил төкерсә, күл була.
* Болгар йорты — Идел йорт,
Идел эче — имин йорт.
* Ватанга хезмәт — үзеңә хезмәт.
* Дустыннан аерылган җиде ел елар,
Иленнән аерылган гомер буе елар.
* Җирсез-йортсыз ил булмый,
Ашсыз-сусыз көн булмый.
* Җир-су дигән җирсендерә,
Йөрәкләрне җилкендерә.
* Җир-суы бар җирен сөйләр,
Ил-йорты бар илен сөйләр,
Ил-йорты юк ниен сөйләр?
* Җир тартмаса, су тарта.
* Зәңгәр бака үз сазын танымас.
* Идел буе бәрәкәтле җир.
* Идел кичми ил булмый.
* Ил аткан таш ерак китә.
* Ил ачуы — яман ачу.
* Ил белән этәргәч, тау күчкән.
* Илгә таянган — Идел кичәр.

## Татарлар һәм Татарстан турында кызыклы фактлар

*1612нче елда немец шәһәре Лейпциг типографиясендә татар телендә беренче китап басылып чыга.*

*Бокс буенча Россиянең беренче чемпионы булып, 1915нче елда, татар боксеры - «Кара малай» кушаматлы Нурмөхәммәт Алимов кала.*

*Нәфис гимнастика буенча Европаның беренче чемпионы булып, 1978нче елда, татар кызы- Галия Шөгерова кала.*

*1927нче елга кадәр татар язуы гарәп графикасына нигезләнә, 1927 елдан 1939нчы елга кадәр латин графикасы нигезендә үсә, ә 1939нчы елдан хәзергә кадәр - кириллица графикасы кулланыла...*

*Япон телендә шундый әйтем бар: «татарча атлау» яки «татар адымы». Ул ниндидер бик мөһим эш яки тәвәккәллек турында сөйләгәндә кулланыла.*





Сергеев Давид, 3 нче В сыйныфы



Мясников Данил, 3 нче В сыйныфы

## Мәктәбебезнең “Сәләт” театр түгәрәге

Безнең “Сәләт” театр түгәрәге 2017 нче елдан бирле эшләп килә. Түгәрәк татар телебезгә карата укучыларның кызыксынуларын арттыру, сөйләм телен баету , иҗади мөмкинлекләрен үстерү максатыннан чыгып төзелде. Төркемгә 5—9 нчы сыйныф укучылары йөри. Бу алдагы еллар кебек атнага ике тапкыр оештырыла. Иң сөендергәне шул бу түгәрәккә татар балалары гына түгел, ә рус балалары да бик кызыксынып , теләп йөри. Күпчелек сәхнә әсәрләребез татар телендә , рус телендә дә куябыз. “Сәләт” театр төркемебез район күләмендә генә түгел, республика конкурсларында да катнашып призлы урыннарга лаек булды.











Безнең уңышларыбыз.


- “Без бергә” Республика балалар-яшүсмерләр фестиваленең муниципаль этабы. 2019, 2020 (I дәрәҗә Лауреат)
- “Тукай иҗаты сәхнәдә”исемле муни.бәйгесе сәхнәләштерү бәйгесе. (Лауреат), 2019
- “ Театр елы-2020"үзешчән коллективлар фестивале. Лауреат, 2020
- “Татарстан халыклары дуслыгы” фестивале, лауреат, лауреат 2020




## Уйнап- уйлап алыйк!



Курчаев Данил , 9 нчы Б сыйныфы



Чухланцев Максим, 9 Б нчы сыйныфы



Курчаев Кирилл, 9 нчы Б сыйныфы



Вертикаль буенча биремнәр
1. Безнең республиканың исеме ничек?
3. Татарстанның башкаласы нинди шәһәр?
6. Баллы татар ризыгы?
7. Казанның 7 катлы истәлекле манарасы?
10.Татар халкының танылган шагыйре (фамилиясе)

Горизонталь буенча биремнәр
2. Татарстанның дәүләт теле?
4. Татарларның милли бәйрәме?
5. Кызларның иң киң таралган исеме?
8. Татарларның дине?
9.Татар хатын-кыз баш киеме?